СОВЕТ АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Центральная, д.28, с. Албай,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422176

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

№ 1-43 16 гыйнвар 2025 ел

Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башлыгының 2024 нчы елда Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башкарма комитеты, Албай авыл җирлеге Советының эшчәнлеге нәтиҗәләре турында отчеты һәм 2025 нче елга бурычлар турында

Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башлыгы Крешков Иван Петрович тарафыннан тәкъдим ителгән 2024елда Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башкарма комитеты, Албай авыл җирлеге Советының эшчәнлеге, шул исәптән 2025 елга бурычлар, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә куелган мәсьәләләрне хәл итү турындагы отчетны тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Советы», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының " Албай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Советы карар бирә:

1.Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башлыгының 2024 нчы елда үз эшчәнлеге һәм Башкарма комитет, Албай авыл җирлеге Советының эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм 2025 нче елга бурычлар турында хисабын расларга.

2. Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башлыгы эшчәнлеген һәм Башкарма комитет, Албай авыл җирлеге Советының 2024 елдагы эшчәнлеген, шул исәптән Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү буенча эшчәнлеген канәгатьләнерлек дип танырга.

3. Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Советы депутатларына Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башлыгының отчетын үз округларында сайлаучыларга җиткерергә.

4. Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- хисап докладында һәм аның турында фикер алышканда әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә һәм депутатларга 2025 елның 1 мартына кадәр җиткерергә;
- җирлек икътисадының барлык тармакларында да эшкуарлыкны үстерү өчен чаралар күрергә ;
- икътисадның тотрыклы, динамик үсеше һәм гражданнар өчен уңайлы мохит булдыру нигезендә халыкның тормыш сыйфатын күтәрүне тәэмин итәргә ;
-район торак пунктларында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүне, гаилә фермалары төзү программаларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

- хокук саклау органнары белән берлектә гражданнарның, шәхси, дәүләт һәм муниципаль милекнең җәмәгать куркынычсызлыгы, тормыш, сәламәтлеге һәм абруен күтәрү буенча алга таба да эш алып барырга кирәк.;
- торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә;

5. Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башлыгының отчет докладын авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://mamadysh.tatarstan.ru к

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башлыгы Крешков И.П. ка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Албай авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.П.Крешков

**Хәерле кон, хөрмәтле Ришат Робертович, депутатлар, килгән кунаклар һәм авылдашлар!**

Безнең авыл җирлегендә бүген ел саен традициягә әйләнгән, районның беренче һәм тармак җитәкчеләре катнашында авыл җыены үткәрелә.

**Бүгенге җыенда түбәндәге көн тәртибе тәкъдим ителә:**

1. Албай авыл җирлегенең 2024 елда эшләгән эшләренә отчеты һәм алдагы 2025 елга эш планнары. Крешков И.П.
2. ФАП житэкчесе Крешкова Тамара Петровна чыгышы.
3. Кама урман хужалыгы житэкчесе чыгышы.
4. СДК житэкчесе Мишурин Геннадий Алексеевич
5. Сорауларга җаваплар. Тармак җитәкчеләре
6. Йомгаклау сүзе белән чыгыш.
7. Бүләкләү.

**Сезне кыскача гына Албай авыл җирлегенең 2024 елда эшләгән эшләренә отчеты һәм 2025 елга эш планы белән таныштырып үтәм.**

Албай авыл җирлеге Советы, үзенең эшчәнлеген, Албай авыл җирлеге Уставына, Совет Регламентына һәм 2024 нче елга төзелгән переспектив планга нигезләнеп эш итте.

Албай авыл җирлеге 4 авылны берләштерә. Албай, Югары Әрнәш,Түбән Әрнәш, Зур Арташ. Авыл жирлегендә барлыгы 226 йорт бар, шуның 113 ында яшиләр, 39 йортта җәйге чорда кайтып яшиләр, 74 йорт буш. (хэр йорнын хужасы бар)

Албай авыл җирлеге территориясендә 1 фельдшерлык пункты, Албай төп мәктәбе, 1 почта бүлекчәсе, Албай авылы мәдәният йорты, 1 балалар бакчасы, 1 библиотека, 2 шәхси кибет халыкка хезмәт күрсәтә.Түбән Әрнәш хэм Югары Эрнэш авылларында кибет булмау сәбәпле килеп сату оештырылган. Кибетләр барсыда Миннеханов Рафаэльнеке. Территориядә 1 чиркәү, 1 музей, 3 зират бар.

Албай авылында 69 хуҗалыкта 150 кеше ( чынлыкта 92 ) , Югары Әрнәш авылында 29 хуҗалыкта 54 кеше (чынлыкта 36), Түбән Әрнәш авылында 10 хуҗалыкта 11 кеше( чынлыкта 8), Зур Арташ авылында 21 хуҗалыкта 45 кеше ( чынлыкта 23) яши. Барлыгы 246 кеше. Шуларның 160 е чынлыкта да авылда яшәүчеләр, ә 86 ы пропискада бездә торып шәһәрдә яшәүчеләр .

Авылда мәктәпкәчә яшьтә 1 бала, мәктәп яшендә 8 бала , 3 студент, 102 пенсионер, 14 эш яшендәге һәм 16 пенсия яшендәге төрле группада булган инвалидлар, 34 кеше эш яшендә.

34 кешенең 19 ы бюджет оешмасында, 5 кеше авыл хужалыгы тармагында , 10 кеше торле тармакларда авыл җирлегендә эшли.

Демографик яктан караганда 2024 елда туучы балалар саны 0, 6 кеше вафат булды. Вафат булучыларнын 6сы дэ пенсия яшендәге кешеләр. 2024 елда 7 кеше пропискадан төште.

Бүгенге көнгә авылда яшәүче халыкның күпчелек өлешен пенсия яшендәге халык тәшкил итә . Бездэ олкэн яшьтэге кешелэр халыкнын 80-85% тэшкил итэ.

Эйткэнемчэ: 102 пенсионер, шулай ук 20 пенсия яшендэге, 14 эш яшендэге – 34 инвалид яши. Пенсионерларнын барчасына да караучылар беркетелгэн.
2 кеше -80 арткан 8 эбине соцзащита аша карыйлар. Алар соцработниклар.
Болар: Светлана Семенова, Айгуль Краснова. Эшлэрен яхшы башкаралар. Замечаниялэр юк.

Хужалыкларда 83 баш мөгезле эре терлек асрала, шуларның 38 сыер малы.
Хуҗалыклар үзләреннән арткан сөтне хөкүмәткә тапшыралар. Бу иң беренче чиратта, аларның үзләренең гаилә бюджетларын тулыландыруның мөһим чыганагы булып тора.
2024 елда иң күп сөт тапшыручы гаиләләрне атап үтәсе килә. Боларга Албайдан Фомин Владимир, Югары Эрнэштэн Краснов Мэлс гаиләләре керә.

Җирлектә 2 һәм аннан да күбрәк сыер асраучы хуҗалыклар бар. 2 сыер асраучылар-7 хужалык, 6 сыер асраучылар: Краснов Мэлс, Фомин Володя.
Албай авыл җирлеге хуҗалыкларда мал асрарга шартлар тудыру турында һәрвакыт кайгыртып тора. Сарыкчылык белэн 5-6 семья шогеллэнэ.
Пай җирләренең хужалары белән ООО “ Агроинпекс” арасында 145 кеше белән договор төзелгән. Договор нигезендә 1 пай җиренә 3000 сум акча түләү каралган. 2024 елга расчет ясалды. 3ц бодай бирелде.
Бүгенге көндә авыл җирлегендә шулай ук 1 үләт базы бар. Ул СанПЭД таләпләренә туры китереп эшләнгән.
Авылда умартачылык гаилә бюджетына иң зур керем кертүче тармак. 9-10 гаилә умартачылык белән шөгыльләнә, умартаны керем чыганагы буларак тота: Назаров Сергей, Семенов Иван, Кирушин Климент һ.б. әлеге тармактан продукция җитештереп шактый зур табыш ала.
Авыл җирлегенең төп вазифаларыннан берсе – авыл халкына матур итеп яшәү өчен шартлар тудыру. Билгеле бу эшләр авыл халкы белән берлектә эшләнә. Шуңа күрә язга чыгу белән авыл халкына экология айлыгы башлануын хәбәр итү өчен дурт авылга да белдерү язып эленә. Экологик икеайлык кысаларында һәр учреждение үз территориясен чүп – чардан арындыра, өмәләр оештырып, урамнарны чистартабыз, баганаларны буйыйбыз. Ел саен дурт авылда да зиратларны чистарту буенча өмәләр оештырыла. Халык бу өмәләрдә теләп катнаша. Бу изге эштә хезмәт күрсәткән һәрберегезгә олы рәхмәтемне җиткерәм.
Авыл җирлеге бүгенге көндә мәдәният йортының эшчәнлеген дә игътибар үзәгендә тота. Мәдәният йорты музыкаль аппаратура, бильярд, шашка, шахмат белән тәэмин ителгән.
Чүп җыюга килгәндә, чүпләрне “Гринта” организациясе башкара. Чүп акчасын пропискада булган барлык кешеләрдән алалар. Графигы –хэр атнанын вторнигында жыела. Машина керә алмый торган урамнар, тыкрыклар бар. Шуна күрә чүпләрегезне олы урамга чыгарып куегыз. Урамнарны кардан үз көчебез белән чистартабыз. Узебезнен МТЗ-82 тракторында икечесе узенен ДТ-75 тракторы белэн Семенов Михаил эшли. Ана ягулык хэм зарплата очен акча каралган.
Хәзер Сезне 2024 елда эшләнгән эшләр белән таныштырып узам.
Тугыз ел инде үзара салым акчасы җыела. Бу акчага эшләнгән эшләр барысы да сезнең күз алдыгызда. Һәрберебезгә мәгълүм булганча үзара салым җыю акчасының авыл җирлекләрен тәртиптә тоту, халыкның көнкүреш тормышын яхшырту өчен күп файда китергәнен һәр елны шул акча хисабына башкарылган эшләребез раслый. Мэсэлэн авыл җирлегендә урнашкан 3 зират, 3 куперне ремонтлау өчен кулланылды. барлык авылларда икешәр чишмә ремонтланды, койма белән әйләндереп алынды, барлык авылларда да урамнарга барлыгы 96 данә диотный лампалар урнаштырылды, релеләр, счетчиклар куелды.

2018 елда җыелган үзара салым акчасына: Албай авылында 4 штук , Югары Әрнәш авылында 2 штук пожарный гидрантлар сатып алынды һәм урнаштырылды. Шулай ук Албай авылында су тутыру емкасте алыштырылды, ә Югары Әрнәш авылында су кудыру башнясы ремонтланды һәм ике авылныкын да рәшәткә белән әйләндереп алынды. Зур Арташ һәм Түбән Әрнәш авыллары арасында урнашкан күпер ремонтланды.
2019 елда жыелган үзара салым акчасына: Албай авылында зират ягына, Югары Эрнэштэ Максимов урамына юл салына башлады.
2020 һәм 2021елларда жыелган акчага бу урамнарда юллар салынып бетте. Шулай ук бу акчага кыш коннендэ дурт авылда да юллар кардан чистартылып тора.
Администрациядэн буленеп бирелгэн 300мен сумга Албай авыл музее ясалып бетте.
Бүгенге көндә авылларны төзекләндерү, яшелләндерү буенча күп кенә эшләр башкарыла. Без дә бу эштән читтә калмаска тырышабыз.
Албай мәдәният йорты эшли башлаганнан бирле ремонт күргәне юк. Үз көчебез белән ел саен өлешчә ремонт үткәрәбез. Менә быел авыл мэдэният йотына капиталь ремонт эшлэре булды.
2021 елда каралган 100мен сумга энергоэкономный лампалар сатып алынды хэм электролениялэр алыштырылды.
2022елда 100мен сумга клубка бер тимер ишек, 4 агач ишек сатып алынды хэм урнаштырылды. Бу эшлэрне “Мамадышстрой” оешмасы башкарды.
Үзара салым акчасыннан бары тик 1-2 гр инвалидлар гына азат ителә, 3 группадан җыела, студентлар очныйлар түләми, заочниклар түли, референдум вакытында пропискада булганнар бүгенге көндә пропискадан төшсәләр дә түлиләр. Күп балалы аналар ( 18 яшькә кадәр 3 баласы булган) азат ителә, толл хатыннар –ирләре сугышта булган, армиядә хезмәт итүчеләр, СВО булучыларнын семьялары льготага ия.
Үзара салым буенча алдагы елга планнарыбыз:
Албай авылында Домолазов урамына юлны таш салып ремонтлап бетеру. Шулай ук бу акча дурт авылда кыш коне юлларны кардан чистартып торуга тотылачак.

Авыл җирлеге шулай ук төрле ярминкәләрдә, ярминкә концертларында актив катнаша. Призлы урыннар яулап, рәхмәт хатлары белән бүләкләнүебез шуның нәтиҗәсе. Җирлектә бәйрәмнәр зур әзерлек белән уза. Яңа ел, Жину бэйрэме, Питрау бәйрәмнәрендә халык теләп катнаша. Узган ел чәй табыны оештырып өлкәннәребез белән матур гына бәйрәм оештырдык. ( Спосарларга зур рэхмэт белдерэм). Район буенча уздырылган барлык чараларда да актив катнашабыз.
Яна ел бэйрэменэ спонсорларыбыз: депутатлар: Яруллин Г. Н. Миннеханов Р.Г, мактэп хэм детсад балаларына куп булэклэр тапшырдылар.
Жину конен оештыруда (сугыш чоры балаларына , тыл ветераннарына пакетлар биру, чэй табыны эзерлэу), Питрау бэйрэмен оештыруда Район житэкчесе Вадим Ильич, депутатлар Яруллин А.Н.,Миннеханов Р.Г., инвестор Ильшат Шавкатовичларнын ярдэме бик зур булды. Инвестор Ильшат 9ел инде бездэ эшли. Ел саен Питрау бэйрэменэ танылган артистлар китертеп кунелле генэ ял оештыра.
Барысына да уземнен исемнэн хэм авылдашларыбыз исеменэн зур рэхмэтебезне белдерэбез.
Эйтеп утелгэн чараларны оештыруда катнашкан бюджет олкэсендэ эшлэучелэр:
Мишурин Г.А.
Мишурина Л.М.
Кибякова Р.И.
Кирушина Л.В.
Крешкова Т.П.га хэм депутатларыбыз:

Абрамов Г.С., Назаров С.П., Краснов М.П., Кирушин К.М.ларга шулай ук зур рэхмэтемне белдерэм. Алга таба да бергэлэп эшлэргэ кунелле итеп ял итэргэ язсын дип телэп калам.
Авыл жирлегендэ узган ел шактый гына эшлэр башкарылды. Бу эшләрнең барысында да авылдашларыбыз актив катнашты. Аларнын хэрберсенә зур рәхмәтләребезне җиткерәбез.
Зиратлар буенча берничэ суз эйтеп китэсе килэ. Ел саен куп гайлэлэр катнашында зиратларны чистарту омэсе оештырыла. Лэкин монда катнашмый калучы гайлэлэр дэ бар. Алдагысы елларда болар моны истэ тотсыннар иде.
Федераль хэм Республика буенча уздырылган программаларда катнашып килэбез. Программа буенча авыл жирлегендэ байтак эшлэр башкарылды.

1. Авыл советы зданиясенэ капиталь ремонт ясалды.
2. Албайда яна ФАП салынды.
3. Спотр площадка сафка басты.
4. 2022елда 10 ел коткэн Т.Болото - Б.Арташ авыллары арасына 2км озынлыкта 19 мил. юл салынды. Безнен купер мэсэлэсе кала. “Берега Укрепления” программасы белэн 2025елда купер дэ салыныр дип ышанып калам.

Мообилизация буенча эйтеп утсэк. Хэзергесе кондэ бездэн бер кеше хезмэт итэ. Ул Митрофанов Артур Ильич. Анын семьясы белэн без ныклы элемтэдэ торабыз. Кирэк булган очракта узебезнен ярдэмебезне курсэтэбез.
Авыл җирлегенең эше күпкырлы. Әйтеп узган эшләр 2024 елда эшләгәннәрнең бер өлеше генә. Алдагы елга планнар белән таныштырып үтәм:

**2025 елга авыл җирлегенең планнары:**

1.Авылларда иң зур проблемаларның берсе булып, яшьләрнең авылда төпләнеп калмавы тора. Бу күп төрле факторларга бәйле. Монда ата – аналар да зур роль уйный. Эш урыннары булмау да бер сәбәп булып тора. Үз эшен башлап җибәрүчеләргә дәүләт ярдәм кулы суза. Авыл жирлегендэ йорт салу яки сатып алу өчен дәүләт программасы эшли башлады.

Шулай ук үз эшен башлап жибәрү өчен бик күп төрле программалар эшли. Кызыксынучылар булса авыл җирлегенә мөрәҗәгать итә аласыз.

2. Район күләмендә җиләк - җимеш үстерү буенча зур эш алып барыла. Без дә үз чиратыбызда шушы эшкә яшь гаиләләрне тарта алсак яхшы булыр иде.
3. Үзара салым акчасын җыеп, Албай авылында юлларга таш түшәү.
4. Албай авыл мәдәният йортына капиталь ремонт ясау.
5. Агачлар утырту.
6. Жину конен, Питрау бэйрэмнэрен оештыру.

Чыгышымны тәмамлап шуны әйтәсем килә, җирлектәге эшне халык белән берлектә эшләгәндә генә уңай нәтиҗәләргә ирешеп була. Килеп туган проблемаларны вакытында, төгәл итеп урыннарда хәл итәргә тырышабыз һәм тырышачакбыз. Алга таба да шушы юнәлешләрне тагын да камилләштереп, замана белән бер аяктан атларга, районыбыз җитәкчелеге белән берлектә, аңлашып, уңышлы гына эшләргә насыйп булсын иде дигән теләктә калам.

Һәрберегезгә исәнлек - саулык, эшегездә һәм тормышыгызда уңышлар телим. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!